**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.04.2016 г.Казань № К-33-1/03-03

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында
хезмәт вазыйфаларын башкару дәүләт серен тәшкил
иткән мәгълүматларны үз эченә алган мәгълүматлардан
файдалану белән бәйле булган һәм аларга билгеләнгәндә
конкурс уздырылмаска да мөмкин булган дәүләт
гражданлык хезмәте вазыйфалары Исемлегенә
үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең урындагы затларын һәм гражданнарын дәүләт серенә уздыру тәртибе турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 6 февралендәге 63 номерлы карары белән кабул ителгән Күрсәтмә нигезендә **боерык бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында хезмәт вазыйфаларын башкару дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматларны үз эченә алган мәгълүматлардан файдалану белән бәйле булган һәм аларга билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска да мөмкин булган дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларының Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2014 елның 4 февралендәге К-12/03-03 номерлы боерыгы белән (2014 елның 14 маендагы К-59/03-03 номерлы, 2015 елның 2 сентябрендәге К-138/03-03 номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Исемлегенә (алга таба - Исемлек) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Исемлекне түбәндәге эчтәлектәге 9 нчы һәм 10 нчы пунктлар белән тулыландырырга:

"9. Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы

10. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлеге башлыгы”.

2. Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлегенә (Слепнева Э.И.) әлеге боерыкка дәүләт теркәве уздырырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз өстемә алам.

Министр Л.Ю.Глухова